ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.08.2022 г.Лениногорск № 786

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 7 июлендәге 630 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөт эшкәртүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында һәм күрсәтелгән субсидияләр һәм 2022 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү үзенчәлекләре турында» 590 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 7 июлендәге 630 номерлы карары белән расланган

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөт эшкәртүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5.2. пунктта:

беренче абзацта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешенә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлеше буенча мәҗбүри тикшерү үткәрү, шулай ук «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы» МКУнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә тикшерүе турында;»;

«б» пунктчасының беренче абзацында «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-18-52